КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 февраль г.Казань № 135

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы; 2015 ел, 21 сентябрь, 693 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 830 нчы; 2016 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2016 ел, 3 ноябрь, 812 нче; 2017 ел, 13 июнь, 374 нче; 2018 ел, 19 февраль, 93 нче; 2018 ел, 21 апрель, 277 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына» сүзләрен «Татарстан Республикасында коммерциячел булмаган оешмаларыга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсын үткәрү буенча республика конкурс комиссиясе составында:

комиссия составыннан И.Ш.Галиуллинны, Р.М.Гарифуллинны, Э.Р.Камалованы, А.Ф.Мөбәрәкшинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановнаны | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасарын |
| Әдһәмова Юлия Илдар кызын | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасарын |
| Миңголов Алмаз Минвазыйх улын | Татарстан Республикасының спорт министры урынбасарын |
| Садыйков Ринат Наил улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министры урынбасарын |
| Тарнавский Егор Александровичны | Татарстан Республикасы экология һәм табигать байлыклары министры урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин